**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**24.07.2019** **№ 1157**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында**

Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташу белән идарә итү һәм җайга салу системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”, 2015 ел, 13 нче июль, 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында”, 2016 ел, 6 нчы сентябрь 887 номерлы карары, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибен (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын (2 нче кушымта);
- Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия турында Нигезләмә ( 3 нче кушымта).

2. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсын Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ адресында урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на заместителя руководителя МКУ «Исполнительного комитета Высокогорского муниципального района Республики Татарстан» Р.Ф. Хакимуллина. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсы җитәкчесе урынбасары Хәкимуллин Р.Ф.га йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Расланган

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
карары белән
24.07.2019 ел №1157

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибе

I. Субсидияләр бирү тәртибен һәм максатларын эшләү нигезе

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 1.2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 нче июнь, 491 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидия исәбеннән барлыкка килгән Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү процедурасын һәм шартларын билгели, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында”, 2013 ел, 5 нче апрель, 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сайлап алынган тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүнең көндәшлекле ысуллары белән сайлап алынган шәхси эшмәкәрләргә Биектау районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында субсидия бирү процедурасын һәм шартларын билгели (алда – Йөртүче, Субсидияләр).

II. Субсидияләр бирү хокукына ия юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр категорияләре

2.1. Субсидияләр алуга түбәндәге категория юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр дәгъва итә ала:

- Россия Федерациясе салым органында тиешенчә теркәлгән;
- 8 (сигез) кешедән артык кеше йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган.

## III. Субсидия бирү шартлары

3.1. Субсидияләр юридик затларга – (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүче шәхси эшмәкәрләргә (алга таба - оешмалар) бирелә, алар субсидия бирү турында түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

- дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законына яраклы рәвештә үткәрелгән башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутларда гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны йөртүне даими рәвештә гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт булу;
- Биектау муниципаль районында даими пассажирлар ташуның маршрут челтәре буенча пассажирларны йөртү буенча хезмәт күрсәтү;
- даими хәбәр маршруты буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесе нигезендә пассажирларны йөртү буенча хезмәт күрсәтү;
- Йөртүченең документлар белән расланган төшеп калучы керемнәре барлыкка килүе;
- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе кануннары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлар булмау;
- Биектау муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән кичектерелгән бурычлар һәм бюджет каршында башка бурыч булмау;
- субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучылар шәхси эшмәкәр икән, шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;
- субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең финанс операцияләрен (оффшор зоналары) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм (яки) бирүне күздә тотмаган ташламалы салым режимы бирә торган дәүләтләрнең һәм территорияләрнең исемлеге мондый юридик затларга карата тулаем алганда 50 проценттан артып киткән устав (склад) капиталында чит ил юридик затларының катнашуы өлеше булган россия юридик затлары булырга тиеш түгел;
- субсиди алучылар әлеге Тәртипнең 1.2 пунктчасында күрсәтелгән максатларга, әлеге Тәртипн нигезендә субсидияләр бирелергә планлаштырылган Биектау муниципаль районы бюджетыннан башка муниципаль хокукый актлар нигезендә акча алырга тиеш түгел.

3.2. Бюджет чараларын алучы буларак баш бүлүче белән субсидияләрне алучы арасында Татарстан Респубикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы, Россия Федерациясе субъектының финанс органы, муниципаль берәмлекнең финанс органының билгеле субсидия төре өчен билгеләнгән типик формасы нигезендә төзелә

(алга таба – Килешү).

3.3. Әлеге Тәртиптә күрсәтелгән субсидияләрне биргәндә, субсидияләр бирү турында шартнамәләргә (килешүләргә) һәм әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатыннан төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләр алучыларның һәм субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне башкару максатыннан төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның рөхсәте (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләре, устав (склад) капиталларында говами-хокукый бермлекләр катнашындагы җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (склад) капиталларында әлеге ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан кала), бюджет чараларын баш бүлүче (бүлүчеләр) – субсидияләр биргән Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органы – Контроль-хисап палатасы тарафыннан аларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен тикшерү тора.

## IV. Субсидияләр бирү тәртибе

4.1. 4.1. Субсидия алу өчен Йөртүче ай саен, хисаптан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, ә декабрь аенда 20 числосына кадәр Комиссия каравына түбәндәге документларны тапшыра:

- субсидия бирү турында гариза;
- пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырудан төшеп калган керемнәрнең әлеге тәртип буенча барлыкка килүен раслаучы исәп-хисап (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта);

4.2. Йөртүче тарафыннан бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча субсидия бирү өчен документларны карау комиссиясе 10 эш көне эчендә төшеп калучы керемнәрне каплауга беркетмә белән рәсмиләштереп, субсидияләр бирү яисә дәлилле баш тарту турында карар кабул итә.

4.3. Килешү төзүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- субсидия алучы тәкъдим иткән документларның әлеге Тәртипнең 4.1 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган күләмдә тапшыру);
- субсидия алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы;
- Йөртүче тарафыннан Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты раслаган тарифның чик дәрәҗәсеннән түбәнрәк тарифларны куллану (алга таба – тарифның чик дәрәҗәсе).

4.4. Кисәтүләр булган очракта Йөртүчегә кисәтүләрне бетерү өчен документлар кире кайтарыла, шул ук вакытта документларны кире кайтару сәбәпләре язма рәвештә күрсәтелә.

Кисәтүләр булган очракта, Йөртүчегә аларны төзәтүгә бирелгән гомуми вакыт, документлар алган көннән алып, 3 календарь көненнән дә артмаска тиеш.

4.5. Субсидияләрне күчерү Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан төшеп калучы керемнәрне каплауга субсидияләр бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 (ун) эш көне эчендә ташучы хисабына

башкарыла.

4.6. Бирелә торган субсидия күләме билгеләнгән тәртиптә киметелергә мөмкин (Биектау муниципаль районы бюджет йөкләмәләре лимитларының һәм бюджет чыгымнарын финанслау күләмнәренең җитәрлек булмавы).

4.7. Субсидия бирү Йөртүченең субсидия бирү турында Килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, автотранспорт предприятиесен бетерү, үзгәртеп кору һәм гамәлдәге Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда туктатылырга мөмкин.

## V. Төшеп калучы керемнәрне кайтару суммасын исәпләү

5.1. 5.1. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы Йөртүченең төшеп калучы керемнәрен каплауга субсидияләр күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча хисаплау юлы белән билгеләнә:

$$С = з\text{-}д$$

биредә:

С - субсидия күләме, мең сумнарда;

З - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 нче июнь, 454 номерлы карары белән расланган транспорт чарасы классына карап 1 км узган юлның иң чик норматив үзкыйммәтен (1 километр өчен 38 сум 27 тиен) һәм маршрутның озынлыгын исәпкә алып, җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар ташуның муниципаль маршрутларда пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга чыгымнар;

Д - җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр, мең сумнарда.

Йөртүченең кереме составына түбәндәге керем төрләре керә:

- муниципаль ташу вакытында пассажирлар йөртүгә һәм багаж алып баруга бер тапкыр билетлар сатудан кергән табыш;
- социаль йөрү билетлары буенча гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле Йөртүченең барлык дәрәҗәдәге бюджеттан бирелә торган чыгымнарын компенсацияләү суммасы.

Шул ук вакытта Йөртүченең керемнәре транспорт чарасын тутыру коэффициентыннан чыгып исәпләнә, 2019 елда ул – 0,4кә, 2020 елда -0,5кә һәм көнгә ике тапкырдан ким булмаган рейс ясауга тигез.

## VI. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

6.1. Йөртүчеләр бирелгән документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән керемнәрнең нигезсез булуы ачыкланган очракта, шулай ук башка контроль чаралар үткәрү, төшеп калучы керемнәрнең фактта барлыкка килгән

керемнәр күләмендә нигезсез чагылышы нәтиҗәсендә субсидияләр рәвешендә алынган бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Субсидияләрне кире кайтару Биектау муниципаль районы бюджетыннан Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан гамәлгә ашырыла торган компенсация түләүләре өчен бүлеп бирелгән субсидияләр арткан очракта гамәлгә ашырыла.

6.2. Ачыкланган кагыйдә бозулар комиссия тарафыннан имзаланган акт белән рәсмиләштерелә һәм Йөртүчегә - субсидия алучыга бирелә.

6.3. Акт алган көннән соң 30 календарь көн эчендә Йөртүче агымдагы финанс елында артык алынган акчаларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының

6.4. Кире кайтарылган субсидияләр суммасы Биектау муниципаль районы бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

6.5. Субсидияләрне кире кайтармаган очракта вәкаләтле орган бюджет акчаларын суд тәртибендә кире кайтару буенча чаралар күрә.

## VII. Контроль

7.1. Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы оешмалар тарафыннан субсидияләрдән файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

7.2. Субсидияләр бирү шартларын бозу яисә аларны максатчан кулланмау очраклары ачыкланган очракта, Вәкаләтле органның язма таләбе буенча субсидияләр бер ай эчендә Биектау муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш. Әгәр субсидия билгеләнгән вакытка кире кайтарылмаган булса, ул Биектау муниципаль районы бюджеты керемenә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

2 нче кушымта

Расланган

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты
карары белән
24.07.2019 ел № 1157

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуга бәйле эшләр башкаруга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында ташучыга субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| 1. Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| 2. Афанасьев Алексей Павел улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. Минһаҗев Салават Марат улы | Икътисад бүлеге начальнигы, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Ганиева Валентина Анатолий кызы | Хисап һәм хисаплылык бүлеге начальнигы |
| 5. Архипов Владимир Димитрий улы | “ТР БМР Советы” МБ МКУ Юридик бүлеге начальнигы |